# КАРАР

Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Түбән Уратма авыл җирлеге составына керүче Түбән Уратма торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

2024 елның 22 октябре № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2024 елның 22 октябрендә уздырылган «Түбән Кама муниципаль районының Түбән Уратма авыл җирлеге Түбән Уратма торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1нче төркем инвалидлар, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлар, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүче солдатлар, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә өлешчә мобилизация буенча хезмәт итәргә чакырылган гражданнарның хатынннарыннан,ирләреннән тыш, 1500 сум күләмендә 2025 елда үзара салым кертү белән килешәсезме. Һәм алдагы эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны:

– Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тору(Түбән Уратма авылындагы юлларны ремонтлау)

ӘЙЕ ЮК».

мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 562 граждан кертелгән, тавыш бирүдә катнашучы гражданнар саны 292 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча җыенда катнашучы гражданнар тавышлары түбәндәгечә бүленде: «Әйе» позициясе өчен халык җыенында катнашкан 292 кеше тавыш бирде; «Юк» позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Түбән Уратма авыл җирлеге составына керүче Түбән Уратма торак пунктында гражданнар җыенын булган дип, халык җыены нәтиҗәләрен чын дип танырга.

«Түбән Кама муниципаль районының Түбән Уратма авыл җирлеге Түбән Уратма торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 нче төркем инвалидлар, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлар, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүче солдатлар, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә өлешчә мобилизация буенча хезмәт итәргә чакырылган гражданнарның хатынннарыннан,ирләреннән тыш, 1500 сум күләмендә 2025 елда үзара салым кертү белән килешәсезме. Һәм алдагы эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны:

– Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тору(Түбән Уратма авылындагы юлларны ремонтлау)

ӘЙЕ ЮК».

Мәсьәләсе буенча карарны кабул ителгән дип танырга.

2. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен мәгълүмат стендларына, Түбән Уратма авыл җирлеге сайтында урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Түбән Уратма авыл җирлеге башлыгы А. Р. Гарифуллин